Azatlıq Radiosı

View the original article

ЯҢАЛЫКЛАР

# Дөнья татарлары Хәтер көне уңаеннан 1552 километр йөгерә

7 октябрь 2026




Хәтер көне, Казан, 1990 елның 14 октябре

**Германиядә яшәүче татарлар быел да #1552run акциясен игълан итте. 1–15 октябрь көннәрендә телләгән һәркем үз шәһәрендә яки авылында йөгереп, узган арасын уртак исәпкә өсти ала. Максат – бергәләп 1552 км җыю.**

Акцияне "Алмания татарча" инициатив төркеме оештыра. Катнашу өчен 1552.tatar сайтында теркәлергә, үзең теләгән ераклыкны йөгерергә һәм нәтиҗәне шунда язып куярга кирәк. Кайда һәм күпме йөгерүне һәркем үзе хәл итә.

— Сәламәт тәндә — сәламәт хәтер! — дип яза оештыручылар үз чакыруында. Алар "төрле илләрдә яшәүче татарларны быел да бергәләп Хәтер көнен билгеләргә" дәшә.

Акция сайтында китерелгән 2024-2025 ел нәтиҗәләренә караганда, йөгерүгә 27 илдән 117 кеше кушылган, алар бергә 1275 км узган.

Оештыручылар сүзләренчә, Германия татарлары бу акцияне 2024 елдан бирле үткәрә. Идея исә Казаннан килә: 2019 елда активист **Наил Нәбиуллин** 52 км йөгереп, "Хәтер марафоны" оештырган иде.

- 1552 елның октябрендә Явыз Иван гаскәре Казанны яулап ала, татарлар үз дәүләтчелеген югалта. 1989 елдан башлап татар җәмәгатьчелеге октябрь аенда Казанны яклап һәлак булганнарны искә алу чарасы – Хәтер көне уздыра. Соңрак аңа чит илләрдәге татарлар да кушылды.
- Хәтер көне рәсми рәвештә Казанда 2022 елдан бирле уздырылмый, хәкимиятләр аны үткәрергә рөхсәт бирми. 2021 елда чарадагы чыгышлар тикшерелгәннән соң Татар иҗтимагый үзәгенә 250 мең сум штраф салынган иде.
- 2025 елда бер төркем кеше Хәтер көне уңаеннан Казанның Иске таш мәчетендә намаз укыган, аннары Татар зиратына барып шәһитләрне искә алып дога кылды.

**🛑 Русиядә Азатлык Радиосы сайты томаланды, нишләргә? Безнең кулланма.**
**🌐 Безнең Telegram каналына да кушылырга онытмагыз!**

This item is part of

яңалыклар | татар-башкорт дөньясы

Азатлык Радиосы © 2026 RFE/RL, Inc. | Бар хокуклар сакланган